# РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
# ДРОЖЖАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
# СОВЕТ БОЛЬШЕАКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

## РЕШЕНИЕ

2015 елның 3 августы № 65/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге федераль законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, прокурорның 22.06.2015 ел, № 02-01-02 протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә Чүпрәле районы прокуроры протестын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Зур Аксу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге Советының 17.10.2008 ел, №45/2 карары белән расланган Нигезләмәгә кертергә. (2009 елның 13 апрелендәге 51/1 номерлы; 2009 елның 25 маендагы 52/2 номерлы; 2013 елның 18 февралендәге 27/1 номерлы; 2013 елның 13 июнендәге 33/1 номерлы;
04 апрель, 2014 ел, №46/4) түбәндәге үзгәрешләр:

а) 3 нче бүлектә:

а) 3.1.1 пунктының 7 пунктчасында «квалификация күтәрү» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу»сүзләренә алмаштырырга;»;

б) 3.2.3 пунктта 3.2 өлеш:

1 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

3 нче пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләреннән һәм профсоюзның билгеләнгән тәртиптә

теркәлгән ширкәтләреннән тыш), әгәр федераль законнарда башкача каралмаган булса яки әгәр дә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән, аңа бу оешма белән идарә итүдә катнашу бурычы куелмаган;»;

2) 5 нче бүлектә:
а) 5.3.4 пунктында 5.3 өлешендә «квалификация күтәрүгә» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу өчен»сүзләренә алмаштырырга;»;

б) түбәндәге эчтәлекнең 5.6 өлешен өстәргә:

«5.6. Муниципаль хезмәт өчен шартнамә нигезендә кадрлар әзерләү

5.6.1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын формалаштыру максатларында җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәт өчен гражданнарны Россия Федерациясенең Мәгариф турындагы законнары һәм әлеге Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып шартнамә нигезендә әзерләүне оештыра алалар.
5.6.2. Муниципаль хезмәтне алга таба үтү йөкләмәсе белән максатчан укыту турында шартнамә (алга таба - максатчан белем бирү турында шартнамә) җирле үзидарә органы белән граждан арасында төзелә һәм укуны тәмамлаганнан соң билгеләнгән вакыт эчендә әлеге җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт узу буенча гражданның йөкләмәсен күздә тота.
5.6.3. Максатчан белем бирү турында шартнамә төзү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла. Максатчан белем бирү турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгара торган матбугат чарасында басылып чыгарга һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органының рәсми сайтында әлеге конкурсны уздыру көненә кадәр бер айдан да соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.
5.6.4. Максатчан белем бирү турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм беренче тапкыр Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары хисабына көндезге уку формасы буенча Урта һөнәри яки югары белем алучы гражданнар ия. Әлеге конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә керү мизгеленә, шулай ук әлеге өлешнең 5 пунктында каралган бөтен срок эчендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.
5.6.5. Максатчан укулар тәмамланганнан соң муниципаль хезмәтне мәҗбүри үтү срогы максатчан укыту турында шартнамә белән билгеләнә. Әлеге вакыт эчендә җирле үзидарә органы гражданга максатчан белем бирү турындагы шартнамә нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәткән, әмма биш елдан артык булмаган сроктан да ким була алмый.

5.6.6. Максатчан укыту турында шартнамә якларының йөкләмәләре һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан укыту турында шартнамә белән билгеләнә.
5.6.7. Максатчан укыту турында килешү гражданин белән бер тапкыр төзелергә мөмкин.
5.6.8. Максатчан укыту турындагы шартнамәдә каралган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Зур Аксу авыл җирлеге башлыгы Храмов Алексей Васильевичка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Зур Аксу
авыл җирлеге башлыгы: А.В.Храмов